ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕКУШКЕТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНАРЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КӨШКӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул. Советская, д. 26, с.Тюнтер, 422242

Совет ур., 26 нчы йорт, Түнтәр, 422242

Тел.: (84368) 3-01-46, факс: (84368) 3-01-14. E-mail: Skush.Blt@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**Хәбәр итү**
**җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар башлау хакында**

Әлеге мәгълүмат белән 16:12:130101:470 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итәбез(алга таба-проект).

**Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге**:

-кадастр номеры 16:12:130101:470 булган җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проекты, мәйданы 619 кв.м., ул түбәндәге адрес буенча урнашкан: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы, Урта Кушкет авылы, Үзәк урам, 2/3 «автомобиль юу урыннары» күпфункцияле иҗтимагый – эшлекле зонада (ОД 4-2) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Урта Көшкет авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм көйләү кагыйдәләренең.

**Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары**:

Проект буенча ачык тыңлаулар 16.07.2026 елдан 04.08.2026 елга кадәр үткәрелә. Гавами тыңлаулар үткәрү процедурасына түбәндәге этаплар керә::

- гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү;
- проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны рәсми сайтка урнаштыру һәм мондый проект экспозицияләрен ачу;
- проект экспозицияләрен үткәрү;
- гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрү;
- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

**Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе**:

Проект буенча гавами тыңлауларда катнашучылар булып:

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Урта Көшкәт авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Урта Көшкәт авыл җирлеге чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;

- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган урыннарның хокук ияләре.

**Гавами тыңлаулар уздырыла торган территория:**

16:12:130101:470 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы проекты буенча ачык тыңлаулар Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Урта Көшкәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә торак пунктның бер өлешендә — Урта Кушкет авылында үткәрелә.

**Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү датасын, вакытын һәм урынын билгеләргә**:

2026 елның 04 августында 13 сәгать 00 минутта авыл мәдәният йортының тамаша залында, Адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы, Урта Кушкет авылы, Үзәк урам, 6 йорт.

**Проектның экпозициясен оештырырга**:

- 29.07.2026 елдан 30.07.2026 елга кадәр Урта Кушкет авылы, Үзәк урам, 6 йорт адресы буенча мәдәният йортында.;

**Гавами тыңлауларда катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше:**

27.07.2026 елдан 30.07.2026 елга кадәрге чорда Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының (алга таба — РФ ГрК) 5.1 маддәсенең 12 өлеше нигезендә идентификация узган гавами тыңлауларда катнашучылар проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы.:

- рәсми сайт аша;

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Урта Көшкәт авыл җирлеге башкарма комитетының гавами тыңлауларын оештыручыга язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә түбәндәге адрес буенча: 422242, РТ, Балтач районы, Түнтер авылы, Совет урамы, 2 йорт, тел. (84368) 3-01-14 (8.00 дән 16.00 гә кадәр);

- РФ ГрК 5.1 маддәсенең 12 өлеше нигезендә идентификация узган гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрү барышында язма яки телдән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы.

Әлеге хәбәрнамәне Балтач районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы муниципаль районының ( http://baltasi.tatarstan.ru ), Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында
( http://pravo.tatarstan.ru ), шулай ук Урта Көшкәт авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, Үзәк ур., 6 й.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгы Перфилов Ю.М.